Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение
«Высокогорский детский сад “Шаян” комбинированного вида
Высокогорского муниципального района Республики Татарстан

# Проект

# «Татар-халык ашлары »

Төзеде:

Галиаскарова Г.Ф

2026 ел

# *Кереш*

Татар халкы бик борынгыдан ук аш-су әзерләргә оста булган, тәмле оригиналь ашлар пешергән. Милли ашларның үзенчәлеге халыкның тормыш рәвешенә бәйле булган. Татарлар элек-электән иген иккән,шуңа күрә оннан, ярмадан ашлар әзерләгән, арыш, бодай, карабодай, борчак, арпа һәм солы онын, тары, карабодай, борчак һәм борай, соңрак дөге ярмасын киң кулланган. Крестьян халкы тарттырмыйча гына борчак белән ясмыктан төрле ашамлыклар әзерләгән. Ит, бигрәк тә сарык,сыер һәм ат(тай) ите татарларның яраткан ашы булган. Яңа суйган терлек итен өстенрәк күргәннәр, әмма җәен,саклар урын булмаганлыктан, тозлы һәм каклаган ит тә кулланганнар. Иттән аш, шулпа пешергәннәр, аштан алган итне еш кына шулпадан соң биргәннәр. Ат итен аеруча яратып ашаганнар, чөнки ул бик туклыклы, халык арасында хәтта ат ите ашаган кеше салкынга бирешми, ару-талуны белми дигән фикер дә яшәгән. Борынгы татар ашлары арасында тавык, каз, үрдәк, күркәдән әзерләнгән ашамлыклар шактый булган,терлек һәм кош итен күбрәк пешереп кулланганнар. Итне бик сирәк, бай татарлар бәйрәм табынына гына кыздырып биргәннәр. Татар ашлары арасында сөт азыклары зур урын алып торган. Ләкин сөтне шул килеш кенә сирәк кулланганнар, чәйгә салып эчкәннәр яисә ашамлыкларга салганнар.Сөттән май язганнар,сөзмә, эремчек, катык, коймак, корт ясаганнар. Татарлар ясаган атлан май бөтен тирә-юньдә дан тоткан. Йомырканы төрлечә пешергәннәр, ашка салганнар,тәбә әзерләгәннәр, камырга һәм төрле бәлешләргә сытканнар. Сабантуй вакытларында ул традицион ашамлык булып саналган. Балыкны азрак кулланганнар. Корбан балыгы, сазан, судак кебек балыкларны кыздырганнар, алардан бәлеш салганнар. Елга балыгыннан тәбә пешергәннәр. Яшелчәләрне күбрәк бәлеш эченә салганнар һәм башка ашамлык янына биргәннәр. Яшелчәләрдән- кабак, чөгендер, суган, шалкан, кишер, ачы торма, кыяр һәм кәбестәне күп кулланганнар. Авыл кешеләре кыргый үләннәрдән: балтырган, кузгалак, кычыткан, кәтүче сумкасы,

мәтрүшкә, кыр суганыннан беренче һәм икенче ашлар, бәлеш эчләре әзерләгәннәр.

Сонгы елларда халкыбызның гореф – гадәтләрен, йолаларын өйрәнүгә, аларны укыту тәрбия эшендә куллануга игътибар артты.Шуна күрә без зурлар төркеме белән татар-халык ашлары дигән темага альбом карарга булдык.Без бу альбомны караганда балалар бик күп сораулар бирделәр, бигрәктә татар-халык ашларының нинди эчлекләр кулланып ясалганын, тагын нинди тәмле ризыклар барлыгын, аның тарихын беләселәре килде. Бу теманы өйрәнер өчен мин 1 ай күләмендә проект эшчәнлеген алып бардым. Балаларга , татар халкының нинди ашлары барлыгын кечкенәдән үк өйрәтергә кирәк.Бу эшне без мәктәпкәчә яшьтәге балаларга өйрәтә башласак бик әйбәт булыр иде .Чөнки бу яшьтә баланың үсеше, хәтере һәм кызыксынучанлыгы бик зур.

**1. Проект төре:** информацион-практик юнәлешле.

**2. Проектның дәвамлылыгы:** 1 ай.

**3. Максат: балаларны татар халык ашлары белән таныштыру.**

**4. Бурычлар:**

1. Пешекче хезмәтенә хөрмәт белән карау. Ата-аналарда балалар бакчасы хезмәткәрләре белән уңай мөнәсәбәтләр булдыру.

2. Төгәллек, игътибарлылык, мөстәкыйльлек, пөхтәлек сыйфатлары булдыру. Үз хезмәтеңнең нәтиҗәсен күреп, горурлану хисе тудыру.

3. Татар халык ашлары турында төшенчә бирү, милли ризыклар турында белемнәрен киңәйтү.

**5.Проектның методлары:**

**Практик юнәлеше**:проект эшчәнлеген алып бару өчен кирәк булган тирә-юнь мохитен булдыру.

**Сүз методы**: Әңгәмә, күзәтү, матур әдәбият уку, табышмаклар, шигырьләр, җырлар өйрәнү, дидактик уеннар, с\р уеннар уйнау.

**Күрсәтмәлек**: күргәзмә, конкурс, шөгыль, күңел ачу бәйрәме, проект өчен материаллар туплау, рәсем, альбомнар карау.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

1. Балалар татар халык ашлары , гореф-гадәтләре турында белемнәрен киңәйтергә.

2. Милли ризык – өчпочмакны, бәлешне һ.б алар әти-әниләр белән өйдә пешереп карарга.

3. Пешекче хезмәтенә ихтирам хисе белән карарга.

4. Балаларда үз хезмәтенең нәтиҗәсен күреп, горурлану хисе уятырга.

5. Балалар ризыкка хөрмәт белән карау, әхлак кагыйдәләрен яхшы белергә.

6. Ата-аналарда балалар бакчасы хезмәткәрләре белән уңай мөнәсәбәтләрне дәвам итү теләген булдырырга.

## 6. Проектның этаплары:

### I. Әзерлек этабы:

- проектның темасын уйлау;
- проектның төрен билгеләү;
- максатын кую;
- бурычларын уйлау;
- перспектив планын язу;
- атрибутлар әзерлә- материаллар туплау;
- пешекчеләр белән сөйләшү;
- әти-әниләрне проект белән таныштыру, биремнәр бирү;
- проектны башкарып чыгу өчен шартлар тудыру.

-әти-әниләр белән анкетирование үткәрү.

- пешекчеләр белән сөйләшү;
- әти-әниләрне проект белән таныштыру, биремнәр бирү;
- проектны башкарып чыгу өчен шартлар тудыру.

- эти-әниләр белән анкетирование үткәрү.

# II. Төп этап

| Атна көннәре | Балалар белән эшчәнлек | Әти-әни белән эш | Әйләнә-тирә мөхитны баету |
|---|---|---|---|
| 8.02 | «Татар –халык ашлары»дигән темага әңгәмә, китап карау. | Әти-әниләрне проектның темасы һәм структурасы белән таныштыру.Анкета тутыру | Дидактик уеннарга атрибутлар ясау турында әңгәмә, өстәмә эдәбият уку. |
| 12.02 | Татар халык ашлары турында табышмаклар, уеннар,макальләр, санамышлар өйрәнү. | Өйгә бирелгән материалны балалар белән ныгыту, атрибутлар ясарга материал җыю. | Д/уен өчен бәлеш, өчпочмак,чәкчәк, кыстыбый ясау(җептән, паралоннан,чүпрәктән) |
| 15.02 | Шигырьлә, җырлар, уеннар өйрәнү. | Д/уен өчен атрибутлар әзерләү. | Татар –халык ашлары турында материал туплап альбом чыгару. |
| 18.02 | «Минем яраткан ризыгым» рәсем конкурсы. | Өйдә балалар белән рәсем ясау. | Рәсемнәрдән күргәзмә ясау. |
| 21.02 | Шөгыль эшчәнлеге «Татар халык ашлары». Өйрәнелгән табышмак,мәкальләрне кабатлау. | Шөгыль өчен: авыл өе куренеше, савыт-саба, скәтер, самавыр, алъяпкыч табырга булышу. | Һәр балага мамык дискларыннан кисеп ябыштырылган чәк-чәкле альбом бите ясау. |
| 27.02 | Әвәләү конкурсы «Оста пешекче» Сценарий буенча җыр «Кунаклар», шигырьләр,бию«Әпипә” өйрәну. | Татар –халык ашларын балалар белән өйдә пешерү. Әти-әни булышлыгы белән сценарий материалын кабатлау. | С/рольле уены «Кафе», «Буфет» өчен кирәкле атрибутларны эшләү.Бәйрәм кичәсенә әзерләнү. |
| 28.02 | Күңел ачу кичәсе «Милли кичә» уткәрү. | Балаларны матур итеп киендереп бәйрәмгә килү. | Кичә өчен пешекчеләр ярдәмендә коймак пешерү.Бәйрәмдә төшкән фота материалларны туплау. |

**Балалар бакчасы хезмәткәрләре, тәрбиячеләр белән эш:**

1. Ашханә бүлмәсенә сәяхәт. Пешекчеләр хезмәтен, аш-су җиһазларын читтән күзәтү (кәстрүл, табалар, сөзгеч, чүмечләр, су баклары, ит тарткыч).

2. Пешекче белән сөйләшү, сөйләшү вакытында пешерү күнекмәләре, куркынычсызлык кагыйдәләре белән танышу.

- пычак белән сак эш итәргә;
- янып торган плитәгә якын килмәскә;
- кайнар әйберләрне бияләй белән тотарга;
- электр приборларына юеш кул белән тотынмаска.

# III этап. Тәмамлау.

**Балалар белән эшчәнлек:**

3. Балалар рәсемнәре конкурсы. «Минем яраткан ризыгым».

4. Балалар белән шөгыль эшчәнлеге. Тема: «Татар халык ашлары »

6.Татар халык ризыкларына конкурс. «Оста пешекче » (Әвәләү)

7.Дидактик уеннар:

- «Өчпочмак ясау өчен нинда яшелчәләр кирәк? »
- «Кунакка чакыру»
- «Пешекче киемен ки»
- «Камыр җәю »
- « Кафе», «Буфет».

8.Балалар белән шөгыль эшчәнлеге «Татар халык ашлары».

9.Күңел ачу кичәсе «Милли кичә».

# ФАЙДАЛЫ һӘМ БИК ТӘМЛЕ ТАТАР ХАЛЫК АШЛАРЫ



## Чәк-чәк



Чәк-чәк тарихы буенча без әлеге ризыкның әзерләү тәртибенең үзләрмәвен күрәбез. Ә менә формасы төрле булырга мөмкин, бу ясаучының зәвыгына карап эшләнелә. Вакытлар үтү белән, әлеге ризыкны бәйрәм ризыгына чутлыйлар,

чөнки ул һәр бәйрәм табынык бизәгән. Әлегрәк бу татлы чәк-чәкне туйларга әзерли торган булганнар, бу кияү һәм кәләш эти-әниләренең мөһим бүләге итеп каралган.   Хәзер исә чәк-чәкне әзерләү өчен аерым бәйрәм яки вакыйга кирәк түгел, әлеге ризык һәр гаиләнең өстәлендә көндәлек ризык.

**Кирәкле әйбер:**

- Он – 400 г.
- 4 данә йомырка.
- Сөт – 67 г.
- Шикәр – 10 г.
- Тоз – 22 г.
- Көнбагыш мае – 210 г.
- Бал – 370 г.
- Шикәр комы – 90 г.

**Әзерләү ысулы:**

Катырак итеп басылган татлы камырны кисәкләргә бүләләр һәм бер сантиметр калынлыкта бау сыман итеп тәгәрәтәләр, аннары вак кына турыйлар, кайнап торган майда саргыт төскә кергәнче болгата-болгата пешерәләр. Балга шикәр комы салып аерым савытта кайнатып алалар. Балның әзерлеген белү өчен, кайнап торган массаны кашык белән алып салкын суга тамызалар, әгәр ул оешса, җәелеп китмәсә, бал әзер була. Әзер төшләрнең өстенә бал сиробы салып болгаталар, киң савытка өеп куеп чәй янына бирәләр.

## Гөбәдия



Гөбәдияне, гадәттә, кунак чакырганда пешерәләр. Гөбәдия - катлам-катлам эчле зур түгәрәк бәлеш. Аның эченә корт (киптергән эремчек), бүрттергән дөге, кыздырган суган белән чапкан ит, ваклап йомырка, йомшартып йөзем, яисә төшен алып өрек яки кара җимеш салалар. Аларның һәркайсын аерым әзерлиләр. Пешкән гөбәдияне кискәч, катламнар аермачык беленеп торырга тиеш. Гөбәдияне әче камырдан да, төче камырдан да ясыйлар, камырга майны күп салалар. Гөбәдия итле һәм җиләк-җимешле була. Җиләк-җимешле гөбәдиягә ит салмыйлар, аны икеләтә югарак ясыйлар һәм чәй янына чыгаралар. Итле гөбәдияне, кайнар килеш, шулпалы аш артыннан бирәләр.

**Кирәкле әйбер:**

- Он – 170 г.
- Май – 25 г.
- Йомырка – 40 г.
- Сөт – 30 г.
- Шикәр комы – 6 г.
- Чүпрә – 5 г.
- Су – 30 г.
- Дөге – 150 г.
- Йөзем – 50 г.
- Йомырка - 120 г.
- Май – 80 г.
- Корт – 170 г.

**Әзерләү ысулы:**

Май, шикәр салып изгән әче камырны ике өлешкә бүләләр. Берсен җәеп майлы табага салалар, өстен майлыйлар. Камыр өстенә таралып торган бүрттергән дөге, аннары корт, вак кына туралган йомырка, йөзем салалар. Эченә эреткән атланмай яисә сары май сибәләр. Гөбәдиянең өстенә җәйгән камыр каплыйлар, кырыйларын табадагы камыр чите белән сырлап, чеметеп ябыштыралар. Өстен берничә җирдән тишкәлиләр, майлыйлар, он белән май катнашмасыннан гыйбарәт балчык сибәләр һәм духовкада пешерәләр. Әзер гөбәдияне кисәкләргә бүлеп, кайнар килеш чыгаралар.

***Татар халкы һәр ял көннәрендә һәм төрле бәйрәмнәрдә кунакларга һәрвакыт бәлеш пешерергә ярата.***



Бәлешне сыер, сарык һәм төрле кош итеннән, балыктан, ярмадан һәм яшелчәләрдән (бәрәңге, кишер, кәбестә һ.б.), җиләк-җимештән пешерәләр. Бәлешне биек итеп тә, тәбәнәк итеп тә, вак кына итеп тә ясыйлар. Биек бәлеш (аны «зур бәлеш» дип тә йөртәләр), гадәттә, шулпалы була. Ярмалы бәлешне табынга табасы белән чыгаралар, башта аның өстен кисеп өләшәләр, аннары, эченә май салып болгаталар да, эчен һәм кырые белән төбен кисеп, һәр кешегә салып чыгалар. Тәбәнәк бәлешне «юка бәлеш» диләр, аны, өлешләргә бүлеп, кеше саен тәлинкәгә куялар.

Кирәкле әйбер:

- Он – 600 г.
- Су яки сөт – 150 г.
- Май – 120 г.
- Бер йомырка.
- Ит – 900 г.
- Бәрәңге – 1500 г.
- Май – 150 г.
- Башлы суган – 180 г.
- Шулпа – 200 г.
- Тоз.
- Борыч.

**Әзерләү ысулы:**

Төче камыр әзерләп, аны ике өлешкә бүләләр. Камырның зуррак өлешен 4-5мм калынлыгында җәяләр дә майлы табага салалар, уртасына бәлешнең эчен салалар. Аннары камырның кечерәк өлешен җәеп өстенә ябалар, кырыйларын чеметеп ябыштыралар. Бәлешнең капкачында тишек тишәләр, шулпа өстиләр, камырдан бөке ясап каплыйлар, өстен майлыйлар да духовкага куялар. Бәлеш 1,5-2 сәгать пешә. Мич кызу булып, бәлешнең өсте көя башласа, өстенә оннан басып җәймә яисә дымлы кәгазь ябалар. Бәлешне табынга бөтен килеш чыгаралар.

# *Татар халкының иң яраткан ризыкларының тагын берсе: өчпочмак.*




Камыр кую Беренче сортлы яки югары сортлы оннан ачы камыр изәләр. Моның өчен җылы суга җылы сөт өстәп, чүпрә, шикәр комы салалар һәм яхшылап болгаталар, йомырка, эретелгән маргарин, тоз салып тагын болгаталар. Башта камыр каймак куелыгында булырга тиеш, аннары аңа иләнгән он өстәп, камырны куерта төшәргә кирәк. Аны, өстән каплап, җылы урында ачыталар. Бер күпереп менгәч, өстен ачып, баскалап куярга кирәк, бер-ике тапкыр шулай эшләргә мөмкин. 1,5-2 сәгатьтән камыр кирәгенчә ачый. 1 кг камыр өчен: 600-

650 г он 20-25 г чүпрә 30 г шикәр комы 1-1,5 йомырка 50-60 г маргарин 100-120г сөт 150-200 г су 10-20 г тоз кирәк булачак.

# Коймак



Ярты литр чамасы кефирны (нинди дә ярый) кайнарланганчы утта тотыгыз. Шуңа бер чеметем тоз, бер аш кашыгы өймичә генә шикәр комы, 1 йомырка салып болгатыгыз. Боларга 3 стакан он өстәгез, ул куе каймак кыяфәтенә керә. Шул массага 1 чәй кашыгы өймичә генә аз-азлап сода салып, болгатыгыз. Аны кайнар табада пешерегез.



Чүпрәне җылы (35-40 градус) суда яисә сөттә изеп, тоз, шикәр комы, йомырка салалар да, әйбәтләп болгаткач, иләгән он салып, камыр изәләр һәм җылы урынга куялар. Камыр кабар башлауга, болгатып шиңдерәләр һәм яңадан җылы урынга куялар. Кабарып, шиңә башлагач, коймакны пешерә башлыйлар. Камыр әйбәт кабарса, коймак, күпереп, йомшак булып пешә. Коймакны...Чүпрәне җылы (35-40 градус) суда яисә сөттә изеп, тоз, шикәр комы, йомырка салалар да, әйбәтләп болгаткач, иләгән он салып, камыр изәләр һәм җылы урынга куялар.Камыр кабар башлауга, болгатып шиңдерәләр һәм яңадан җылы урынга куялар. Кабарып, шиңә башлагач, коймакны пешерә башлыйлар. Камыр әйбәт кабарса, коймак, күпереп, йомшак булып пешә. Коймакны мичтә, духовкада һәм плитәдә пешерергә мөмкин. Мичтә яки духовкада коймакны әйләндермичә генә пешерәләр, аның асты-өсте берьюлы кызара, табаны гына боргалап торырга кирәк. Плитәдә пешергәндә, кыздырган майлы табага кашык белән 60 г чамасы камыр салып, өсте алсуланганчы башта бер ягын, аннары, әйләндереп, икенче ягын кыздырып пешерәләр.Коймакны май, каймак, бал, варенье белән бирергә мөмкин.

# Көтелгән нәтиҗәләр:

1. Балалар татар халык ашлары , гореф-гадәтләре турында күбрәк белделәр.

2. Милли ризык – өчпочмакны,бәлешне алар әти-әниләр белән өйдә пешереп карадылар, аның эчлеге турында белделәр.

3. Пешекче хезмәтенә ихтирам хисе туды.

4. Балаларда үз хезмәтенең нәтиҗәсен күреп, горурлану хисе уянды.

5. Балалар ризыкка хөрмәт белән карау, әхлак, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләренә өйрәнделәр.

6. Ата-аналарда балалар бакчасы хезмәткәрләре белән уңай мөнәсәбәтләрне дәвам итү теләге артты.

# Файдаланылган әдәбият:


1. Гаиләдә, балалар бакчаларында әдәплелек тәрбияләү программасы: Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен. – Казан: Мәгариф, 2005.
2. Әхлак нигезе – матур гадәт (Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбияләү): Методик кулланма / К. В. Закирова, Р. Ә. Кадыйрова. – Казан: Мәгариф, 2004.
3. Иң матур сүз: Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2000.
4. Балалар фольклоры / Төз. Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.
5. Кабыргалы-камчылы: Татар халык уеннары. – Казан: Мәгариф нәшр., 2002.
6. Мәктәпкәчә тәрбия: Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләү / Төзүчесе К. В. Закирова. Фәнни редактор Ф. Ф. Харисов. – Казан: РИЦ “Школа”, 2000.

# Кушымта

## Табышмаклар.

**Й**омырка белән онны
Бутап камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар.   (Өчпочмак)

Утырсам да мин менә
Тыйнак кына, тик кенә.
Эчем тулы ит кенә,
Май белән, дөге белән. (Бәлеш)

Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың.
Ул нәрсә?    (Коймак)

Камыр эчендә бәрәңге
Йә, уйлап кара әле. (Кыстыбый)

Иттән генә торам мин
Майга чумып чыгам мин.  (Пәрәмәч)

Вак-вак кына итеп кисеп,
Өяләр аны таудай!
Чак-чак кына алып, өзеп
Аша, дустым, син шулай.  (Чәк-чәк)

## Викторина

Бутап камыр басалар.
Эченә: бәрәңге, ит, тоз салып
Почмаклар ясаганнар.
- Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың. Ул нәрсә?
Сызгыра,пошкыра,
Өстәлемдә,парлар атып,
Кунак көтеп утыра. (Самовыр)
Йомырка белән онны
Бутап камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар. (Өчпочмак)

1төркемгә:
Үзе түгәрәк,
Урыны түрдәрәк,
Эче тулы күзәнәк,
Бар нәрсәдән кадерлерәк. (Ипи)
Иттән генә торам мин
Майга чумып чыгам мин. (Пәрәмәч)
2 төркемгә:
Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың.
Ул нәрсә? (Коймак)
Утырсам да мин менә
Тыйнак кына, тик кенә.
Эчем тулы ит кенә,
Суган белән бәрәңге. (Бәлеш)

2нче бирем: Кроссвордны чишәргә. Һәр дөрес җавап өчен 1 балл бирелә. Сулдан уңга:3)Гөбәдия пешергәндә кулланыла торган,сөттән әзерләнгән ашамлык (Корт).
5) Эченә бәрәңге боламыгы ягып пешерелә торган камыр ашы (Кыстыбый)
6)Бәрәңге һәм иттән пешерелә торган милли ризык (Өчпочмак).
Өстән аска:1)Баллы төш. (Чәк-чәк)2)Ашка салу өчен әзерләнгән нечкә һәм озынча камыр телемнәре (Токмач). 3) Дини бәйрәмнәрдә иң элек пешерелә торган таба ризыгы (Коймак).
4) Эченә ит,бәрәңге салып әзерләнгән түгәрәк камыр ашы (Бәлеш).
3нче бирем: һәр төркем өстәлдә булган милли ризыкны әзерләү тәртибен аңлатырга тиеш.
1төркем-бәлеш,2-бавырсак,3-гөбәдия.
Төркемнәрнең җавапларын тыңлау.Дөрес ингредиентлар һәм әзерләү тәртибе өчен төркемнәр балл ала ала.
4енче бирем. Уен-табышмак »Бер сүз белән әйт».
– Эченә бәрәңге, тары ярмасыннан эчлек салып пешергән ашамлык (Кыстыбый)
-Милли татар ашамлыгы (Өчпочмак)
-Бик үзенчәлекле ашамлык, аны күбрәк шәһәр халкы әзерли. Эчлеге кат-кат итеп тезелә (Гөбәдия)
– Күркәм ризык, туй мәҗлесенең бизәге (Чәк-чәк).
– Иң борынгыдан саналган эчемлек (Әйрән).
– Җиләк-җимешне кайнатып, сөзеп ясала торган ризык (Как.)
– Көн саен кулланыла торган ризык, аннан башка ашау үтми, аңа халык дан җырлый (Икмәк, ипи).
– Туйларда чәк-чәкне алыштыра торган ризык (Бавырсак).
– 2 сүздән тора, татар халкының милли ризыгына керә (Кош теле).
– Аш пешергәндә кулланыла. Татар халкына хас камыр ризыгы (Токмач).

5 енчы бирем: «Дәвам ит!»уены
1төркем:
Безгә кунаклар килсен,
Һәркем уйнасын- ... (көлсен)Өстәлгә куйыйк чәчәк,
Аның янына ... (чәк-чәк)
2төркем:
Кош теле һәм өчпочмак.
Сыйлансын килгән ... (кунак)
Киеник матур итеп:
Аякка чиккән-... (читек)
3 төркем:
Түбәтәй,калфак киик,
Бер матур итеп ... (биик)
Бар да безне күрсеннәр,
Булдырасыз ... (дисеннәр)
6нчы бирем. « Адашкан» уенын уйнау.
Хәрефләрне тиешле тәртиптә урнаштырып, сүзне җыярга.
Камөчпоч- өчпочмак
Әшлеб-бәлеш
Сытбыкый-кыстыбый
Кәч-кәч-чәк-чәк
Мачток-токмач
Кыравбас-бавырсак
7нче бирем:шигырьләрне сәнгатьле итеп уку.
1төркем:
Гөжләп утыра самавыр
Табынга зур ямь бирә.
Гәпләшеп чәй эчә-эчә
Кич утырабыз бергә.
2 төркем:
Килгән һәркемне сыйлыйбыз
Куе кайнар чәй белән.
Җанга рәхәт,тәнгә шифа,
Эчсәң аны бал белән

## Уен-табышмак «Бер сүз белән әйт».

- Эченә бәрәңге, тары ярмасыннан эчлек салып пешергән ашамлык (Кыстыбый)
-Милли татар ашамлыгы (Өчпочмак)
-Бик үзенчәлекле ашамлык, аны күбрәк шәһәр халкы әзерли. Эчлеге кат-кат итеп тезелә (Гөбәдия)
- Күкәм ризык, туй мәҗелесенең бизәге (Чәк-чәк).
- Иң борынгыдан саналган эчемлек (Әйрән).

- Көз өмәсе табынының бизәге (Тәбикмәк).
- Җиләк-җимешне кайнатып, сөзеп ясала торган ризык (Как.)
- Көн саен кулланыла торган ризык, аннан башка ашау үтми, аңа халык дан җырлый (Икмәк, ипи).
- Туйларда чәк-чәкне алыштыра торган ризык (Катлама).
- Ике сүздән тора, татар халкының милли ризыгына керә (Кош теле).
- Аш пешергәндә кулланыла. Татар халкына хас камыр ризыгы (Токмач)1.

# Ата-аналар өчен анкета.

- 1.Сез нинди татар халык ашларын беләсез?
- 2.Сез өйдә нинди татар халык ашлары әзерлисез?
- 3.Сезнең балалар нинди татар халык ашларын ярата?
- 4.Тиз әзерләнә торган нинди татар халык ашларын беләсез?
- 5.Милли ризыклар пешергәндә балаларыгыз сезгә булышамы?

Анкетада күренгәнчә әти-әниләрнең 50% беренче сорауга татар-халык ашларының төрләре турында белемнәре барлыгын белдерде, икенче сорауга әти-әниләрнең 40% өйдә һәрвакыт бәлеш һәм өчпочмаклар, кыстыбый, пәрәмәч пешерүе турында ачыкланды. Өченче сорауга килгәндә балаларның 40% бәлеш, өчпочмак яратса, тиз әзерләнә торган ризыклардан коймакны 60% әти-әни атады. Әти-әниләрнең 10% аш-су пешерү өлешендә баларының катнашканың язды.Шулай итеп анкетага нәтиҗә ясаганда , әти-әниләр татар-халык ашларын бик еш булмасада пешерә, ләкин бу ашларның торлелеген һәм файдасы турыда бик аз белүләре, кечкенә буынга татар халкының гореф-гадәтләрен өйрәтүдә бик аз өлеш кертүләре ачыкланды

# Зурлар төркемендә шөгыль.

| | |
|---|---|
| **Тема:** | **«Татар халык ашлары** » |
| Интегральләштерелгән белем бирү өлкәсе: | музыка, танып белү, сөйләм теле, матур әдзбият,физик үсеш.. |
| Төре: | Сөйләм телен үстерү. |
| Максат: | Татар халык ашларын өйрәнүне ныгыту. |
| Бурычлар: | 1.Сөйләм телен үстерү.<br>2Балаларны татар халкының мили ризыклары белән таныштыруны дәвам иту (чәк-чәк, коймак, өчпочмак, бәлеш).<br>3.Уен аша чәк-чәк ясау.<br>4.Татар халкының милли ризыкларына кызыксыну уяту, балаларның иҗади сәләтен үстерү.<br>5.Балаларның күңелләрен күтәрү. |
| Эшчәнлек барышында кулланылган методик алымнар һәм формалар: | Балалар игътибарын җәлеп итү, әңгәмә,сораулар,күзәтү, күрсәтү,физминутка,уен. |
| Җиһазлау: | Авыл өе куренеше, милли ризык муляжлары, савыт-саба, скәтер, самавыр, алъяпкыч, һәр балага мамык дискларыннан кисеп ябыштырылган чәк-чәкле альбом бите, бертапкыр кулланыла торган чәй пакетлары, салфетка, су һ.б. |
| Шөгыль төзелеше һәм структурасы: | 1.Исәнләшү.Хәерле иртә теләү.<br>2.Тизәйткечләр әйтү.<br>3.Интерактив тактада уен. «Нәрсә югалды».<br>4.Ял минуты.<br>5.Макальләр әйтү.<br>6.Бавырсак белән сыйлану.<br>7.Җыр җырлау. «Без әзерлибез табын».<br>8.Йомгаклау.<br>9.Мактау. |
| Алдан башкарылган эш: | Әниләр турында шигырь ятлау, матур әдәбият уку, портретлар карау. |
| Киләчәктә эшләнәсе эшләр: | Балаларны портретның төрле жанрлары белән белән таныштыру эшен дәвам итү. |

**Эшчәнлек барышы:**

«Әссәләмәгәләйкүм» җыры (Госман Садә сүзләре, Резидә Әхиярова музыкасы) астында балалар бүлмәгә керә, ярымтүгәрәк астында тезелеп утыралар.

**Тәрбияче:** Тел ачкычы иман биргән,

Сөекле туган телем.

Үз телемдә сиңа сәлам –

Әссәләмәгәләйкүм.

**Балалар:** Әссәләмәгәләйкүм.

**Тәрбияче:** Балалар,бүген безгә бик куп кунак апалар килгән, алар белән дә матур итеп исәнләшеп алыйк әле.

**Балалар :** Исәнмесез! Хәерле көн!

**Тәрбияче:** Ә хәзер бер беребезгә матур итеп елмаеп алабыз да, урыннарыбызга утырабыз.

Балалар, бүген бик күп сөйләшергә, сөйләргә туры киләчәк, шуңа күрә телләребезне шомартып алыйк әле:

Са-са-са саескан су сала.

- Тизәйткечне дэ кабатлыйбыз:

Мич башында биш мәче,

Биш мәченең биш башы.

Биш мәченең биш башына

Ишелмәсен мич ташы.

- Бүген без сезнең белән татар халкының милли ризыклары – «Татар халык ашлары” белән танышырбыз.

Минем иң беренче сезнең татар халык ашларын күргәнегез, ишеткәнегез, нинди татар халык ашларын ашаганыгыз бар, шуларны ишетәсем килә.

(Балалар үз белгәннәрен сөйлиләр).

**Тәрбияче:** Рәхмәт, балалар. Сезнең бу ризыкларны татып караганыгыз, алар турында ишеткәнегез, күргәнегез бар икән.

Ә хәзер экранга карыйк әле. Сез анда нәрсәләр күрәсез?

(балалар җавабы).

*Д/уен* **«***Нәрсә югалды?*» *(өчпочмак, пәрәмәч, бәлеш, чәк-чәк) яки “***«***Дөресен сайлап ал*».

**Тәрбияче:** Балалар, ә бу ризыкларны нәрсәдән әзерлибез соң? Моны белү өчен мин узем янына ике баланы чакырам. (Колакларына бер ризык исемен әйтәм алар шул ризыкны әзерләү өчен нәрсәләр кирәк, өстәлдән сайлап алалар, калган балалар әйтергә тиеш була, дөреслеген тикшерү өчен ашъяулык белән каплыйм дөрес булса ризыкның муляжы хасил була. Балалар кычкырып исемнәрен кабатлыйлар (өчпочмак, бәлеш,чәк-чәк).

**Тәрбияче:** Ә нигә өчпочмакны **«**өчпочмак» дип әйтәләр?

**Балалар:** Чөнки өч почмагы бар.

**Тәрбияче:**Бүлмәдә өчпочмакка охшаган нәрсәләр бар?(балалар жавабы)

**Тәрбияче:**Бәлеш белән өчпочмак ничек аерыла?

**Балалар:** Өчпочмакның өч почмагы бар, ә бәлеш – түгәрәк.

**Тәрбияче:** Бүлмәдә түгәрәк нәрсәләр күрәсез?(балалар җавабы)

- Бүген без сезнен белән чәк-чәкләр ясарбыз.

Чәкчәк – ул татар халкының иң дәрәҗәле ризыгы, чәк-чәк белән мәртәбәле кунакларны каршы алалар. Бүген без аны ясау серләренә төшенербез.

Сез чәкчәк яратысызмы?

**Балалар:** Мин яратам, ул тәмле.

**Тәрбияче:** Раяз, син яратысыңмы чәк-чәк?

Чыннан да чәкчәкне барыбыз да ярата, ул һәр бәйрәмнең (туй, туган көн һ.б.) түрендә, ул бик тәмле, ә шулай да ул файдалымы?

**Балалар:** Әйе.

**Тәрбияче:** Ни өчен файдалы?

**Балалар:** Чирләгәндә баллы чәкчәк белән чәй эчәләр.

**Тәрбияче:** Ә күп ашасаң, файдалымы?

**Балалар:** Юк.

**Тәрбияче:** Ни өчен файдалы түгел дип уйлыйсың, Зәлия?

**Балалар:** Күп ашасаң, тешне сызлата, кулга буяла.

**Тәрбияче:** Балалар, әйдәгез кулларны ял иттереп алабыз да эшкә тотыныйк. Ял минуты:

Жиннәрне сызганабыз,
Ашка токмач басабыз.
Менә шулай, менә шулай
Ашка токмач басабыз;
Без камырны жәябез,
Менә шулай, менә шулай,
Без камырны жәябез;
Э хәзер без токмачны кисәбез
Менә шулай, менә шулай
Без токмачны кисәбез.

- Рәхмәт, балалар. Әйдәгез өстәлләр артында уз урыныгызны алыгыз әле. Шушы матур чәк-чәкләргә төс кертәбез (бер кулланышлы пакетлы чәйләр белән).

(Балалар эше, татар халык музыкасы астында эш башкарала, мактау, хуплау сүзләре).

**Тәрбияче:** Балалар, бик матур итеп эш башкардыгыз. Бигрәк күпереп, алсуланып пеште чәкчәкләрегез. Сезнең эшләрегезгә карап өстәлләрегездә кояш елмая, эшегезнең нәтижәсен шул кояшка карап белерсез.

- Әйдәгез әле эш турында мәкальләр әйтешеп алыйк.
- Кем эшләми – шул ашамый;
- Тырышкан табар – ташка кадак кагар;
- Тирләп эшләсән – тәмләп ашарсын;
- Эш агачы хәрвакытта – бик юмарт китерер жимеш;

**Тәрбияче:** Балалар, чыннан да халык мәкальләрендә хак сузләр, сез тырышып эшләдегез, шуның өчен дә мин сезне татар халкының милли

ризыгы – бавырсак белән сыйлыйм. Бавырсак ул нәрсәгә охшаган – чәкчәккә, бавырсакны ачы камырдан ясыйлар, майда пешерәләр.

Балалар, без сезнең белән нәрсә турында сөйләштек?

Бүгенге көнебез сезгә ошадымы? Нәрсәсе күбрәк ошады?

**Тәрбияче:** Рәхмәт, балалар, булдырдыгыз. Ял көннәрендә әниләрегез татар халкының милли ризыкларын пешергәндә ярдәм итәрсез. (Вакытка карап өйрәнгән шигырьләрне сөйләтү) Жыр белән бетә «Без әзерлибез табын».

- Жырлыйк әле, биик әле,
Балачак ул – матур чәчәк.
Байлык, муллык билгеседер
Өйләрдә баллы чәкчәк.
- Майдай йомшак күңелебез
Балдай татлы телебез.
Чәкчәк кебек бердәм булып
Дус яшәргә телибез.

**Тәрбияче:** Сез бүген нәрсәләр турында белдегез?Бигрәк тә сезгә нәрсәләр охшады?

Шуның белән безнең шөгылебез тәмам .Булдырдыгыз балалар .Әфәрин!

# Күңел ачу кичәсе.

**Тема. «Милли ризыклар».**

**Максат:** Бәйрәм хисе тудыру, балаларның белемнәрен камилләштерү.

Кичә, татар халык ашлары белән танышканнан соң, зурлар төркеме балалары белән уздырыла. Балалар барысы да милли киемнәрдән. Залда татар халык ашларыннан күргәзмә оештырыла.

*Алып баручы.* Балалар, безнең әби-бабаларыбыз, эти-әниләребез кул эшләренә, жырга-биюгә бик сәләтле булу белән бергә, аш-суга да оста булганнар, тәмле ризыклар пешергәннәр. Милли ашларның үзенчәлеге халыкның тормыш рәвешенә бәйле булган. Бүген бездә гадәти булмаган кичә. Бездә кунакта – татар халык ашлары.

*1 нче бала*. Бәйрәмсез бик күңелсез бит,
Күңелсездер сезгә дә.
Бәйрәмнәр кирәк безгә дә
Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә
Кирәк һәммәбезгә дә.
*Роберт Миңнуллин*

*2 нче бала*. Зурлап олы бәйрәмне
Жыелды татлы ашлар.
Гөбәдия, бәлешләр,
Пәрәмәч, өчпочмаклар.

*3 нче бала.* «Алан» бакчасына
Жыелдылар күп булып.
Утыралар тезелеп,

Кабарып, өстәл тулып.
Залга гөбәдия, чәк-чәк, кош теле, бәлеш, өчпочмак, коймак, пәрәмәч булып киенгән балалар керә.

**Җыр: «Кунаклар»** (Ш. Галиев сүзләре, С. Сабирова музыкасы).

Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын.
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына — чәкчәк.
Бавырсак һәм кош теле.
Ризыклар төрле-төрле:
Сумса, бәлеш, өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак.
Һәркемгә чыгар өлеш:
Бар кыстыбый һәм бәлеш!
— Җитешегез, кунаклар,
Кыстатмагыз, кунаклар!
Өйгә кайтып китәргә
Ашыкмагыз, кунаклар!

*4 нче бала.* Менә табын түрендә
Гөбәдия күренде.
Йөзе шат, көлеп тора,
Хуш ис бөркелеп тора.

*5 нче бала.* «Табын яме — чәк-чәк» дигән
Сүзләр йөри тугелме?
Һәрбер туйның иң түрендә
Урын ала түгелме?

*6 нчы бала.* Баллы чәк-чәккә күңеле
Күтәрелә кызларның.
Хәзер инде тыпыр-тыпыр
Биисе бар аларның.

*Алып баручы.* Ә хәзер «Парлашып калу» уенын уйнап алырбыз. Көй уйнаганда барыбыз да таралып, иркенләп биеп йөрибез; ә көй туктагач, парлашып калырга онытмагыз. Кем парсыз кала – ул сорау ала (татар халык ашлары турында).

«Парлашып калу» уены.

*7 нче бала.* Без әзерлибез табын
Китереп бөтен шартын.
Өчпочмак, бәлеш, коймак –
Кем әйтеп бирер икән,
Нәрсәләр җитми тагын?

*Алып баручы.* Нәрсәләр җитми икән, түгәрәккә басып, чиратлашып әйтеп карыйк әле. Бер әйткән камыр ризыгын кабатламаска тырышыгыз.

*Алып баручы.* Әйдәгез, ял итеп алыйк, бераз биеп тә карыйк.

**Татар халык биюе «Әпипә»**

*Кош теле.* Табын түрен һәрчак бизи
Майда пешкән кош теле.

Авыз итми һич тә китми
Килгән кунак, билгеле.
*Бәлеш.* Утырсам да мин менә
Тыйнак кына, тик кенә,
Эчем тулы ит кенә,
Май белән, дөге белән.
*Пәрәмәч.* Итгән генә торсам да,
Майга чумып чыксам да,
Мин да бик тәмле булам.
*Бөккән.* Менә мине әйткәндә,
Мин бит төрлечә булам:
Бер пешкәндә — ит белән,
Бер алма белән тулам.
Мине дә тәмле, диләр,
Табынның яме, диләр.

**Җыр: «Кояшлы табын»** (Р. Курамшин көе, Э. Шәрифуллина сүзләре).

*Ак әби керә* (милли киемнән, кулында — чигүле сөлге белән коймак).

— Кулымда яңа гына табадан төшкән, кабарып, кызарып пешкән коймаклар. Коймак ул – бик кадерле, мәртәбәле ризык.

Коймак пеште,
Табадан төште.
Кунакларга сый-хөрмәт,
Якты чырай, такта чәй.

*Алып баручы.* Рәхмәт, Ак әби, без бу коймаклар белән төркемдә чәй эчәрбез. Әйдәгез әле бергәләп «Коймаклар» уенын уйнап алыйк.

**«Коймаклар» уены.**

Булатның туган көнендә
Без чакырдык кунаклар.
Кунакларның килүенә
Без пешердек коймаклар.
Коймакларга карасаң,
Менә шулай күпергән,
Менә шулай җәелгән,
Менә шулай кысылган.
Коймагыңны майлап ал,
Теләгәнеңне сайлар ал!

*Ак әби.* Балалар, мин сезгә өчпочмак ясау серләрен әйтеп китим әле. Өчпочмак гадәттә әче камырдан ясыйлар. Сарык я бозау итен вак кына турыйлар. Бәрәңгене әрчеп, югач турыйлар. Иткә бәрәңге, суган, май, тоз, борыч салып болгаталар. Камырны чәй тәлинкәсе кадәр җәяләр. Камыр уртасына эчен салалар да өчпочмак ясап, чеметеп, ябыштыралар. Ясап бетергәч, майлаган табага тезеп, духовкага тыгалар. Өчпочмак бер сәгать чамасы пешә.

*Алып баручы.* Ак әби, синең киңәшләреңне истә тотып, өйгә кайткач өчпочмак пешереп ашарбыз әле. Ә хәзер балалар белән »Күрсәт әле, үскәнем» уенын уйнап алыйк.

**«Күрсәт әле, үскәнем» уены.**

Күрсәт әле, үскәнем ничек суган турыйлар,
Менә шулай, менә шулай суган турыйлар.
Күрсәт әле, үскәнем ничек бәрәңге турыйлар,
Менә шулай, менә шулай бәрәңге турыйлар.
Күрсәт әле, үскәнем ничек ит турыйлар,
Менә шулай, менә шулай ит турыйлар.

*Ак әби.*Сез бик тәрбияле балалар икәнсез. Бик сөендем. Минем дә сезгә әйтәсе килгән сүзем бар.

- әти-әнидән алда табын янына килеп утырмагыз;
- әти-әнидән алда ашка сузылмагыз;
- ипи валчыгын коеп ашамагыз, ипинең рәнҗүе төшәр;
- сыныгыгызны ашап бетерегез, югыйсә бәхетегез калыр;
- вакытында туя бел, кашыгыңны куя бел.

*Алып баручы.* Ак әби, зур рәхмәт сиңа! Бу үгет-нәсыйхәтләреңне истә тотарбыз. Бүгенге кичәдә без татар халкының милли ашларына дан җырладык. Без аларны кадерләсәк, хөрмәтләсәк кенә рәхәт яшәячәкбез.

# Фотоматерал

**Әти-әниләр белән бергә татар-халык ашларын өйдә пешерү. Тәмледә соң өчпочмаклар һәм бәлеш.**





# Сюжетлы/рольле уен «Кунак чакыру»





# С/рольле уен «Кафе»



# Рәсем конкурсы «Минем яраткан ризыгым»







Балалар белән әвәләү



